СОВЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 40 от 28.01.2021
на № _от ________

# КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районының административ комиссиясен
төзү турында

“Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 14 статьясындагы 1 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетын административ комиссия төзү өчен вәкаләтле орган итеп билгеләргә.

2. Саба муниципаль районының Башкарма комитетына:

– административ комиссия төзергә;
– административ комиссия составын расларга;
– административ комиссиянең эш регламентын расларга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарны “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе М. Р. Ишниязовка йөкләргә.

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р. Н. Минниханов